СОВЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 2а, д.Нижние Аты ,
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 2а йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422016

Тел. (84366)5-07-35, факс (84 3665-5-07-35). E-mai Sat.Ars@tatar.ru

**18 апрель 2016 ел** **№ 18**

**Урта Аты авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**Урта Аты авыл җирлеге Советының 03.11.2014 № 69 карары белән расланган Урта Аты авыл җирлеге Советы аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Урта Аты авыл җирлеге Советы аппаратында һәм авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 03 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында Урта Аты авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Урта Аты авыл җирлеге Советының 03.11.2014 № 69 карары белән расланган Урта Аты авыл җирлеге Советы аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Урта Аты авыл җирлеге Советы аппаратында һәм авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

в)үз чыгымнары, шулай ук җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүматлар тапшыру елыннан алдагы календарь ел дәвамында - әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге өч ел эчендә әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә һәм әлеге алыш-бирешләр кылган акчалар алу чыганаклары турында.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Урта Аты авыл
җирлеге башлыгы Мухамадиев Я.З